**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» апреля 2022г. с. Тюлячи № 59

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү хакында

ДБУ «Татарстан Республикасында киңлек (пространство) күрсәткечләре фонды» ның 2022 елның 27 гыйнварындагы 127/07 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 1 пунктының 15 пунктчасы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясының 1 өлеше, Теләче муниципаль районы Уставы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә,аларга карата 1 номерлы кушымтада күрсәтелгән генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына (2 номерлы кушымта) генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән, 1 номерлы кушымтадагы авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча чаралар планын раларга.

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән, 1 номерлы кушымтадагы авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләр Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбенә гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«05» 04 2022 № 59
карарына 1 номерлы кушымта

Генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре исемлеге

| № т/б | Авыл җирлеге исеме | Авыл җирлеге Советының генераль планнарны әзерләү зарурлыгы булмау турындагы карары |
|---|---|---|
| 1. | Әбде авыл җирлеге | № 65 29.03.2022 |
| 2. | Айдар авыл җирлеге | № 49 01.04.2022 |
| 3. | Баландыш авыл җирлеге | № 54 01.04.2022 |
| 4. | Олы Мишә авыл җирлеге | № 57 01.04.2022 |
| 5. | Олы Нырсы авыл җирлеге | № 51 01.04.2022 |
| 6. | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге | № 57 10.03.2022 |
| 7. | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге | № 57 10.03.2022 |
| 8. | Иске Җөри авыл җирлеге | № 57 10.03.2022 |
| 9. | Шәтке авыл җирлеге | № 78 10.03.2022 |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«05» 04 2022 № 59
карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча чаралар планы

| № т/б | Чараның исеме | Башкаручы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | 9-АЖ генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул итү | Башкарма комитет | 1 эш көне |
| 2. | Теләче муниципаль районы ТПС на үзгәрешләр кертә башлау турында карар кабул итү | Башкарма комитет | 1 эш көне |
| 3. | Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан техник биремне раслау | Башкарма комитет | 1 эш көне |
| 4. | Территориаль планлаштыру схемасын нигезләү материалларын эшләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү проектын эшләүгә контракт төзү | Башкарма комитет | 5 эш көне |
| 5. | Теләче муниципаль районының ТПС торак пунктлары чикләрен, карталарын һәм текст материалларын формалаштыру | Киңлек (пространство) мәгълүматлары фонды | 2 ай |
| 6. | Татарстан Республикасы буенча ФДБУ «Росреестрның ФКП» нда торак пунктлар чикләре тасвирламалары | Киңлек (пространство) мәгълүматлары фонды | 7 эш көне |
| 7. | Территорияне планлаштыруның ФДМС на ТПС үзгәрешләр кертү проектын урнаштыру һәм куелган материаллардан файдалана алуны тәэмин итү | Башкарма комитет | 1 эш көне |
| 8. | Проект буенча җыелма бәяләмәне килештерү һәм алуны башкару | Башкарма комитет | 2 ай |
| 9. | ТПС үзгәрешләр кертү проектын раслау | Башкарма комитет | 5 эш көне |
| 10. | Торак пунктларның чикләре турында белешмәләр БДКМР (ЕГРН) кертү | Башкарма комитет | 15 эш көне |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев